БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                КАРАР

02.08.2024                136

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә
берьяклы хәрәкәт билгеләү турында

«Автомобиль юллары һәм Россия Федерациясендә юл эшчәнлеге, Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына ярашлы, шулай ук Баулы шәһәре территориясендә юл хәрәкәте куркынычсызлыгын арттыру һәм юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмау максатларында, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 1 сентябреннән Баулы шәһәренең Островский тыкрыгы буйлап Первомайская урамыннан Пушкин урамына кадәр хәрәкәт юнәлешендә берьяклы хәрәкәт билгеләргә.

2. Баулы шәһәре «Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе» МКП-сенә Эчке эшләр Министрлыгының Баулы муниципаль районы буенча Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе белән килештерелгән схема буенча, юл билгеләре кую эшләрен оештыруны йөкләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы сайтында bavly.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе                И.И. Гозәеров